Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Булдырь авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 65/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча чыгарырга:
-Йолдыз поселогы, Центральная тыкрыгы, 2А бина (административ бина);
-Йолдыз пос., Полевая ур., 1;
-Булдырь авылы, Центральная ур., 51Д;
-Булдырь авылы, Центральная ур., 27 йорт.

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Булдырь авыл җирлеге
башлыгы Н.Н. Воляков

Чистай муниципаль районы
Булдырь авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
65/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Булдырь | Булдырь авылы<br>Центральная, Мәскәү, 1 нче Гусевка, 2 нче Гусевка, Карьер, Ключевая, Бродовка, Зелёная урамнары. | 72 |
| 2 | 2 нче Садовый | Змеево авылы<br>Садовая ур., СТ Кама тер. 82 нче йорт, 92 нче йорт, 27 нче участок, Дси ОНТ Урожай 100 нче йорт, СНТ Речник 318 нче йорт, Психинтернат урамы №1, №2, №4, №5 йортлар, 3 нче бина. | 86 |
| 3 | 3 нче Овражный | Йолдыз пос.<br>Совхоз ур., Овражная ур., Центральная тык. | 72 |
| 4 | 4 нче Совхоз | Йолдыз пос.<br>Комсомол ур., 1 нче йорттан №7, №7А йортына кадәр, Специалисты тык. №1, №2, №3 йортлар. | 83 |
| 5 | 5 нче Комсомол | Йолдыз пос. Комсомол урамындагы 8 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, Специалисты тык. 4 нче йорт, 5 нче йорт. | 80 |
| 6 | 6 нчы Полевой | Йолдыз п. Специалисты тык. №6, №6а, №7, №8, №9 йортлар, Полевая ур., Широкая урамы 1 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр. | 86 |
| 7 | 7 нче Широкий | Йолдыз пос. Широкая урамы №10 йорттан №21 йортка кадәр, Молодежная урамы №11, №13, №15 йортлар. | 79 |
| 8 | 8 нче Молодёжный | Йолдыз пос. Молодежная урамы 1 нче йорттан 10 нчы йортка кадәр, №12, №14, № 16, №17, №18, №20, №22, №24, №26, №28, №28, №29 йортлар, Молодежная тыкрыгы, №2, №4 йортлар. | 83 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | 9 нчы Дальний | Йолдыз пос. Дальняя урамы, Победа урамындагы 4 нче йорттан 17 нче йортка кадәр. | 74 |
| 10 | 10 нчы Новосельский | Йолдыз пос. Новосельская урамы, Победа урамы, 18 нче йорттан 32 нче йортка кадәр, Савельев ис. ур. 45 нче йорт. | 72 |



с. Змеево
Комсомольский 5
3 Овражный пер.
6 Полевой
8 Молодежный
Совхозный пер. 4
Широкий 7
9. Дальний
Новосельский пер. 10
п. Юлдуз
Булдырский округ №1
с. Булдыри
394
120
395
122
125
128
127
13
515
140
25
85
8
76
14
16
17
22
248